ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» 184-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары М.Һ. Галиев, Р.Г. Хөсәенов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» 184-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы М.Г. Әхмәтов

Казан шәһәре
2026 елның 22 июле
№ 672-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
М.Һ. Галиев,
Р.Г. Хөсәенов
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2011, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 5; 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2025, № 56 (I өлеш), № 75 (I өлеш); 2026, № 1 (I өлеш), «гомумтаралган файдалы казылмалардан һәм минераль эчәргә яраклы сулардан тыш» сүзләрен «гомумтаралган файдалы казылмалардан, минераль эчәргә яраклы сулардан һәм шифалы ләмнәрдән тыш» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законның 14 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2026 елның 10 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә эшләнде.

Әлеге Федераль законда шифалы ләмнәр чыгаруны һәм (яисә) реализацияләүне гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларына (алга таба – КУЭ субъектлары) «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясында каралган финанс ярдәме бирү мөмкинлеге беркетелә.

Татарстан Республикасында КУЭ субъектларына финанс ярдәме «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба – ТР законы) 14 статьясы нигезендә КУЭ субъектлары йөкләмәләре буенча субсидияләр, бюджет инвестицияләре, дәүләт һәм муниципаль гарантияләре бирү юлы белән Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджетлар акчалары, шулай ук КУЭ субъектларына ярдәмгә Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр бирү очрагында, Россия Федерациясе бюджеты акчалары исәбеннән күрсәтелә.

ТР Законының гамәлдәге 9 статьясы нигезендә финанс ярдәме, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан башкасы каралмаган булса, гомумтаралган файдалы казылмалардан һәм минераль эчәргә яраклы сулардан тыш, файдалы казылмалар чыгаруны һәм (яисә) реализацияләүне гамәлгә ашыручы КУЭ субъектларына күрсәтелә алмый.

Шул ук вакытта «Табигый дәвалау ресурслары, дәвалау-савыктыру җирлекләре һәм курортлар турында» 1995 елның 23 февралендәге 26-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясы нигезендә шифалы ләмнәр минераль сулар кебек үк табигый дәвалау ресурсларына карый.

Моңа бәйле рәвештә закон проектында ТР Законының 9 статьясындагы 3 өлешенә шифалы ләмнәр чыгаруны һәм (яисә) реализацияләүне гамәлгә ашыручы КУЭ субъектларын финанс ярдәме күрсәтелә алмый торган КУЭ субъектлары арасыннан төшереп калдыра торган төгәлләштерүче үзгәреш кертү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яисә яңаларын кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнар таләп итми.